РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » 02 2021 № 34

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 ел, 19 сентябрь, 351 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалар тәрбияләүче гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатыннан һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясе 2021 ел, 4 гыйнвар, ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 ел, 19 сентябрь, 351 нче карары белән расланган, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә (16.10.2015, № 346; 25.04.2016 , № 225; 20.03.2017, № 188; 09.01.2018, № 01;18.12.2019 , № 852 үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2 бүл. 2.1 п. «Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе» түбәндәге эчтәлекле L) абзац өстәргә: «L) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев